КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 21 сентябрь г.Казань № 706

2018 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Уңайлы шәһәр мохиты формалаштыру» өстенлекле проектын тормышка ашыру чаралары турында

2018 – 2022 елларда Татарстан Республикасында «Уңайлы шәһәр мохиты формалаштыру» өстенлекле проектын тормышка ашыру һәм 2018 – 2022 елларда Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохиты формалаштыру дәүләт программасын формалаштыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгәннәрне расларга:

2018 – 2022 елларда төзекләндерергә тиешле ишек алды территориясен 2018 – 2022 елларда Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохиты формалаштыру дәүләт программасы проектына кертү хакында тәкъдимнәрне тапшыру, карап тикшерү һәм бәяләү тәртибе һәм вакытлары;

2018 – 2022 елларда төзекләндерергә тиешле җәмәгать территориясен 2018 – 2022 елларда Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохиты формалаштыру дәүләт программасы проектына кертү хакында тәкъдимнәрне тапшыру, карап тикшерү һәм бәяләү тәртибе һәм вакытлары;

2018 – 2022 елларда Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохиты формалаштыру дәүләт программасы проекты турында җәмәгать фикер алышуы тәртибе.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына 2018 – 2022 елларда Татарстан Республикасы территориясендә заманча шәһәр мохиты формалаштыру дәүләт программасы проектын формалаштыруны тәэмин итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин